ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

4 март, 2024 ел № 32/8

Шәһәр Советының 2022 елның 2 ноябрендәге 17/8 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.2, 29.4 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/10 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә шәһәр төзелешен проектлау нормативларын әзерләү, раслау һәм аңа үзгәрешләр кертү хакында Нигезләмә нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2022 елның 2 ноябрендәге 17/8 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 14 - 16 пунктларны көчен югалткан дип танырга;

2) 17 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«17. Проект документациясе составы территорияне планлаштыру проектын эшләү өчен техник биремдә билгеләнә.»;

3) 18 пунктның беренче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«18. Проект документациясе сызымнарында билгеләнә:»;

4) 2 таблицага искәрмәләрнең 3 пунктында «эскиз тәкъдимендә» сүзләрен «проект документациясендә» сүзләренә алыштырырга;

5) 99 пунктта «эскиз тәкъдимендә» сүзләрен «проект документациясендә» сүзләренә алыштырырга;

6) 11 таблицада:

- «Мәгариф оешмалары биналарының диварларыннан магистраль урамнарның кызыл линиясенә кадәр ара кимендә 25 м булырга тиеш» сүзләрен «Мәгариф оешмалары биналарының диварларыннан (җир участогы чикләреннән) магистраль урамнарның кызыл линиясенә кадәр ара кимендә 25 м булырга тиеш»;

- искәрмәнең 2 пунктында «эскиз тәкъдимендә» сүзләрен «проект документациясендә» сүзләренә алыштырырга;

7) 16 таблицага искәрмәдә «*Исәп-хисап күрсәткечләре СП 42.13330.2016 нигезендә кабул ителә.» сүзләрен «*Исәп-хисап күрсәткечләре СП 42.13330.2016 нигезендә кабул ителә, җәя эчендә II дәрәҗә планировка берәмлеге (торак микрорайоны) күрсәтелгән.» сүзләренә алыштырырга;

8) 17 таблицага искәрмәдә «*Исәп-хисап күрсәткечләре СП 42.13330.2021 нигезендә кабул ителә» сүзләрен «*Исәп-хисап күрсәткечләре СП 42.13330.2016 нигезендә кабул ителә» сүзләренә алыштырырга;

9) 18 таблицага искәрмәдә «*Исәп-хисап күрсәткечләре СП 42.13330.2021 һәм СП 396.1325800.2018 нигезендә кабул ителә» сүзләрен «*Исәп-хисап күрсәткечләре СП 42.13330.2016 һәм СП 396.1325800.2018 нигезендә кабул ителә.» сүзләренә алыштырырга;

10) 193 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«193. Торак микрорайоннар (комплекслар), торак йортлар төркемнәре, аерым торак биналар территорияләрендә халыкның җиңел автомобильләре өчен машина урыннары саны түбәндәге нормадан чыгып билгеләнә: фатирларның гомуми мәйданының 55 кв.метрына 1 машина урыны, кунаклар өчен машина кую урыны күпфатирлы торак йортның 600 кв.метрына 1 машина урыны.

Җиңел автомобильләр саклау урыннарында кирәкле санда буш урыннар булганда, җәяүлеләр үтемлелеге 800 метрдан артмаган очракта һәм машина кую урыннарына гомуми ихтыяҗның 10 проценттан артыграк булмаган санда, проектлаштыру территориясеннән читтә паркингларда һәм гаражларда машина кую урыннарын урнаштыру рөхсәт ителә. »;

11) 298 пунктта «СП 134.13330.2012» сүзләрен «СП 134.13330.2022» сүзләренә алыштырырга;

12) 377 пунктның 5, 6 пунктчаларын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5) проект документациясен эшләгәндә һәм караганда;

6) проект документациясен проектлаганда һәм килештергәндә, социаль, транспорт, инженерлык инфраструктурасы объектларының эш проектларына экспертиза үткәргәндә;»;

13) 382 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«382. Расланган планлаштыру проекты чикләрендә урнашкан территорияләрдә проект документациясе әзерләгәндә территорияне планлаштыру проектын раслау датасына гамәлдә булган Җирле нормативлар кулланыла.»;

14) 383 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«383. Территорияне планлаштыру буенча документациягә үзгәрешләр керткәндә аның аерым өлешләрен раслау рөхсәт ителә.».

2.Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев